**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘРБӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**№ 7** **10.03.2015 ел**

**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләрнең этика һәм хезмәт тәртибе кодексына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 29 декабрендәге ПУ-1100 номерлы Указы нигезендә һәм алга таба муниципаль хезмәт өлкәсендәге мәсьәләләрне җайга салуны камилләштерү максатларында Аксубай муниципаль районының Шәрбән авыл җирлеге Советы

карары:

1. Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлеге Советының «Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең этикасы һәм хезмәт тәртибе кодексы турында»25.04.2011 ел, № 5 карары белән расланган Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең этикасы һәм хезмәт тәртибе Кодексына үзгәрешләр кертергә.

2. Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең этикасы һәм хезмәт тәртибе кодексының 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

"Татарстан Республикасы муниципаль хезмәтенә керүче Россия Федерациясе гражданы кодекс нигезләмәләре белән танышырга һәм аларны үз хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашырганда, шул исәптән «Интернет»мәгълүмати - телекоммуникацион челтәрен кулланып үтәргә тиеш».

3. Әлеге карарны Аксубайның рәсми сайтында бастырып чыгарырга муниципаль район http:aksubayevo.tatarstan.ru

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Аксубай муниципаль районы
Шәрбән авыл җирлеге башлыгы Д.А. Шәрифуллин